ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е　　　　　　　　　　К А Р АР

2021 елның «27» апреле　　　　　　　　　　№414

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын яңа редакциядә раслау турында» 2019 елның 08 августындагы 1112 номерлы карары белән расланган баланы (балаларны) матди карап тору, опекунга (попечительгә), тәрбиягә бала алган ата-аналарга, шулай ук опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә бала алган ата-аналарга, үз вазыйфаларын түләүле нигездә башкаручы тәрбиягә бала алган ата-аналарга акча билгеләү һәм түләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын яңа редакциядә раслау турында» 2019 елның 08 августындагы 1112 номерлы карары белән расланган баланы (балаларны) матди карап тору, опекунга (попечительгә), тәрбиягә бала алган ата-аналарга, шулай ук опекуннарга яки попечительләргә, тәрбиягә бала алган ата-аналарга, үз

вазыйфаларын түләүле нигездә башкаручы тәрбиягә бала алган ата-аналарга акча билгеләү һәм түләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.5. пунктта «4» пунктчаны Йорт кенәгәсеннән өземтә (әгәр документ коммерция оешмалары тарафыннан бирелә икән) төшереп калдырырга;

2.6. пунктта (хакимият органнары карамагында булган мәгълүматлар):

«Йорт кенәгәсеннән өземтә» яки «йорт кенәгәсеннән өземтә (әгәр документ җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән булса)» сүзләрен яшәү урыны буенча теркәлү турында мәгълүматлар-Россия Эчке эшләр министрлыгы» сүзләре белән алмаштырырга;

2.5. пунктта «2» пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. 14 яшькә җитмәгән мөрәҗәгать итүче гаиләсенең барлык әгъзалары өчен бала туу турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары»;

3.4.1 пунктта (ведомствоара соратып алулар юнәлеше):

«йорт кенәгәсеннән өземтәләр» сүзләрен «яшәү урыны буенча теркәлү турында мәгълүматлар» сүзләренә алмаштырырга».

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары В.В. Друкка йөкләргә.

Җитәкче З.Г. Михайлова

О.В. Назарчук
5-04-13